**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ
ТЕРКӘЛДЕ

МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ЗАРЕГИСТРИРОВАНО
"02" 09. 2014 г.
ТЕРЧ № РЕГИСТРАЦИОННЫЙ 2407

**ПРИКАЗ**

**19.08.2014**

**БОЕРЫК**

**№ 01-02/312**

**“Татарстан Республикасы”, “Татарстан” атамаларын һәм алар нигезендә барлыкка килгән сүзләрне һәм сүзтезмәләрне (шул исәптән кыскартылмаларны) юридик затлар исемнәрендә куллануга Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәт күрсәтүләренең Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2012 елның 14 июнендәге № 01-02/40 боерыгы белән расланган административ регламентына үзгәрешләр кертү турында**

“Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законның 26.3 статьясына һәм “Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру турында” Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында” 2013 елның 21 декабрендәге № 359-ФЗ Федераль закон нигезендә БОЕРЫК БИРӘМ:

1. “Татарстан Республикасы”, “Татарстан” атамаларын һәм алар нигезендә барлыкка килгән сүзләрне һәм сүзтезмәләрне (шул исәптән кыскартылмаларны) юридик затлар исемнәрендә куллануга Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы тарафыннан рөхсәтләр бирү буенча дәүләт хезмәт күрсәтүләренең Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2012 елның 14 июнендәге № 01-02/40 боерыгы белән расланган административ регламентына (22.10.2013 № 01-02/130 боерык белән кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 нче бүлектә:

3 бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3. Административ процедураларны (гамәлләрне) үтәүнең составы, өзлеклелеге һәм сроклары, аларны үтәүгә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон рәвештә үтәүнең үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны күп функциональ үзәкләрдә үтәүнең үзенчәлекләре”;

түбәндәге эчтәлекле 3.6 пункт өстәргә:

“3.6. Күп функциональ үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтелми.”.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны юстиция министрының беренче урынбасары Р.И.Заһидуллинга йөкләргә.

Министр Л.Ю.Глухова